ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЕЛАБУЖСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АЛАБУГА МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

01.12.2021 № 88

Россия Федерациясе бюджет системасы
Бюджетларына түләүләр буенча бурычлар
булу (булмау) турында салым түләүчеләргә
мәгълүмат бирү эшен оештыру турында

Федераль салым хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе белән Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районының 2021 елның 26 гыйнварындагы 21-21/32 номерлы мәгълүмати хезмәттәшлек турында килешүен гамәлгә ашыру максатларында, Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының структур бүлекчәләренә дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне сорап мөрәҗәгать иткәндә, Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына түләүләр буенча бурыч булу (булмау) хакында салым түләүчеләргә мәгълүмат бирү эшен оештырырга.
2. Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының инвестицион үсеш бүлегенә 2021 елның 4 февраленнән дә соңга калмыйча Татарстан Республикасы дәүләт идарәсенең цифрлы үсеше, мәгълүмати технологияләр һәм элемтә министрлыгына Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2012 елның 7 августындагы 674 номерлы карары белән расланган дәүләт хезмәтләре күрсәткәндә һәм Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары дәүләт вазыйфаларын башкарганда ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек Тәртибе нигезендә ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлекне оештыруга заявка (гариза) җибәрүне тәэмин итәргә.
3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Алабуга муниципаль районы бБшкарма комитеты җитәкчесенең икътисадый үсеш буенча урынбасары Т.В. Никоновка йөкләргә.

Җитәкче Л.Ф. Нургаянов